ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгы турында» 2001 елның 24 гыйнварындагы 595 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2001, № 1 – 2; 2005, № 1 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2010, № 5 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2020, № 87 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар» сүзләренә алмаштырырга;

2) 1 статьяда:
а) сигезенче абзацта «эшкәртелмәгән һәм яңадан эшкәртү узмаган» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) унбишенче абзацта «җир кишәрлекләре милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяда:
а) исемдә «җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларның» сүзләренә алмаштырырга;
б) беренче абзацта «Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләрен «Җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыл хуҗалыгы җирләре составындагы һәм авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдаланыла торган яисә бирелгән башка категория җирләр составындагы җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар мондый җир кишәрлекләре турында Авыл хуҗалыгы җирләре һәм авыл хуҗалыгын алып бару өчен файдаланыла торган яисә бирелгән башка категория җирләр составындагы җирләр турында бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан (алга таба – Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасы) билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат алырга;»;

4) 4 статьяда:

а) исемдә «җир кишәрлекләре милекчеләренең, җирдән файдаланучыларның, җир биләүчеләрнең һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларның» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Җир кишәрлекләре милекчеләре, җирдән файдаланучылар, җир биләүчеләр һәм җир кишәрлекләрен арендалаучылар» сүзләрен «Җир кишәрлекләре хокукына ия булучылар» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасына «Авыл хуҗалыгы җирләренең уңдырышлылыгын тәэмин итүне дәүләт җайга салуы турында» 1998 елның 16 июлендәге 101-ФЗ номерлы Федераль законның $22^2$ статьясында күрсәтелгән мәгълүматны тапшырырга;»;

г) сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга;

5) 7 статьяда:

а) бишенче абзацта «җир кишәрлекләре милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) унбишенче абзацта «җир кишәрлекләре милекчеләренә, алардан файдаланучыларга, аларны биләүчеләргә һәм аларны арендалаучыларга» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

6) 12 статьяда:

а) дүртенче абзацта «җир кишәрлекләре милекчеләрен, җирдән файдаланучыларны, җир биләүчеләрне һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларны» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «җир кишәрлекләре милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир биләүчеләргә һәм җир кишәрлекләрен арендалаучыларга» сүзләрен «җир кишәрлекләре хокукына ия булучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

7) $15^1$ статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Авыл хуҗалыгы җирләре дәүләт реестры авыл хуҗалыгы җирләре турында системалаштырылган дөрес белешмәләр җыелмасыннан гыйбарәт.»;

б) икенче өлештә «федераль законнар нигезендә» сүзләреннән соң «Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен өстәргә;

8) түбәндәге эчтәлекле $15^2$ статья өстәргә:

«$15^2$ статья. **Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасы**

Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасын булдыру һәм аның эшләве федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы Бердәм федераль дәүләт мәгълүмат системасына мәгълүмат тапшыра.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «в» һәм «г» пунктчаларыннан һәм 7 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының «в» һәм «г» пунктчалары һәм 7 пункты 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 20-ТРЗ